РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Школьная, д.5, с.Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс (84396) 4-22-23 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

**№109** **18.09.2023 ел**

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы карары

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 октябрендәге №10 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктату турында» 2023 елның 31 июлендәге №389-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Кармыш» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 октябрендәге №10 карарының «Салым ставкалары» 2 статьясының 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән (җир кишәрлегенең күчемсез милек объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3% (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».
2. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Р.Гатина